ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**10.12.2025**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 3443**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 13 мартындагы 628 номерлы карары белән расланган Административ комиссия тарафыннан «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына салынган административ штрафларны түләү буенча бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тану һәм аларны исәптән төшерү хакындагы карарларны кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 10 октябрендәге 1360 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 13 мартындагы 628 номерлы карары белән расланган (2021 елның 22 ноябрендәге 2977 номерлы карары, 2024 елның 10 июндәге 1549 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Административ комиссия тарафыннан «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына салынган административ штрафларны түләү буенча бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тану һәм аларны исәптән төшерү хакындагы карарларны кабул итү тәртибенә (1 нче кушымта)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә :

1.1. 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Административ комиссия тарафыннан «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына салынган административ штрафларны түләү буенча бурыч (алга таба – түләү буенча бурыч) ышанычсыз дип таныла һәм түбәндәге очракларда исәптән төшерелергә тиеш:

1) физик затның - бюджетка түләүләр түләүченең үлеме яисә аны Россия Федерациясе граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат дип игълан итү;

«2)«Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау - бюджетка түләүләр буенча ул күрсәтелгән Федераль закон нигезендә түләү бурычын үтәүдән азат ителгән бурыч өлешендә;

3) бюджетка түләүләр түләүче оешманың бетерелүе - Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә оешма мөлкәтенең җитмәве һәм (яисә) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан түләнә алмавы аркасында түләнми калган бюджетка түләүләр буенча бурычлар өлешендә;

4) штрафка тарту рәвешендә җәза алуга хөкем ителгәннәргә карата амнистия яисә ярлыкау турында актлар куллану яисә суд тарафыннан бюджет керемнәре администраторының бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеге югалуы өчен, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы чыгуга бәйле рәвештә, нигез булган карар кабул ителү;

5) 2007 елның 2 октябрендәге «Башкару эшчәнлеге турында» 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кайтарганда, күләме банкротлык турындагы эш буенча производство кузгату өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычлар күләменнән артмаган бурыч барлыкка килү датасыннан биш елдан артык вакыт узса, суд приставы-башкаручы тарафыннан башкарма документны кире кайтару турында карар чыгару;

6) бурычлыны банкрот дип тану турында гаризаны кире кайтару яисә банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны уздыруга суд чыгымнарын капларлык акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне үтәтүне туктату турында суд тарафынн акт кабул итү;

7) оешманың мөлкәте җитмәгәнлектән һәм Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан аны түләп бетерү мөмкин булмау сәбәпле түләнмәгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә- - юридик затны теркәү органы карары буенча юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан чыгарылуы һәм 2007 елның 2 октябрендәге «Башкару эше турында» 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкарма документны түләттерүчегә кире кайтарылу сәбәпле, башкару эшен төгәлләү турында суд приставы – башкаручы тарафыннан элек

чыгарылган суд приставы-башкарма карары булуы». Юридик затны 2001 елның 8 августындагы «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәве турында» 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турында теркәүче орган карары гамәлдә түгел дип танылган очракта , әлеге пунктча нигезендә түләтерү ышанычсыз дип танылган бюджетка түләүләр буенча бурыч , бюджет (бухгалтерлык) исәбендә торгызылырга тиеш»;

1.2. 3.1 пунктының «а» подпунктында «отчетлылык өземтәсе» сүзләрен «белешмә» сүзе белән алыштырырга.

1.3. 3.1 пунктының «б» пунктчасын «Россия Федерациясенең Бюджет кодексының 1601 статьясына ярашлы билгеләнгән бюджетка түләүләр буенча дебиторлык бурычын, пеняларны һәм штрафларны түләтү буенча бюджет керемнәре администраторының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламенты белән каралган» сүзләре белән тулыландырырга;

1.4. 3.1 пунктының «в» пунктчасында җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«амнистия турында акт яки штраф формасында җәзага хөкем ителгәннәргә карата ярлыкау акты яисә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалта торган суд акты»;

1.5. 3.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«гражданга карата судтан тыш банкротлык процедурасы тәмамлану турында Бердәм федераль банкротлык турында реестрдан белешмәләрне үз эченә алган документ».

2. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтәләр бүлеге начальнигына әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин